# КАРАР

**14 ноябрь 2023 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегенең Яңа Ашыт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 2023 елның 14 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

" Сез 2024-нче елда Яңа Кенәр авылы территориясендә яшәгән урында теркәлгән һәр олы кешедән 600 сум күләмендә үз-үзегезгә салым салырга ризалашасызмы, 1-нче төркем инвалидларын исәпкә алмаганда, гражданнар 80 яшь, инвалид балалар, сугыш ветераннары, Чернобыль атом электр станциясендә булган аварияне бетерүдә катнашучылар, түләү күләме 300 сум үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы? Түбәндәге эш:

1. Урам-юл челтәрендәге юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю Яңа Ашыт авылы:

- Җинү урамы (100 м);

- Вахитов урамы (50 м).

« ЭЙЕ» «КАРШЫ»

Гражданнарның җыен (йомгаклау беркетмәсе) беркетмәсе нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 87 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 46 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 46 кеше тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Яңа Ашыт авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип.

2. " Сез 2024-нче елда Яңа Кенәр авылы территориясендә яшәгән урында теркәлгән һәр олы кешедән 600 сум күләмендә үз-үзегезгә салым салырга ризалашасызмы, 1-нче төркем инвалидларын исәпкә алмаганда, гражданнар 80 яшь, инвалид балалар, сугыш ветераннары, Чернобыль атом электр станциясендә булган аварияне бетерүдә катнашучылар, түләү күләме 300 сум үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы? Түбәндәге эш:

1. Урам-юл челтәрендәге юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю Яңа Ашыт авылы:

- Җиңү урамы (100 м);

- Вахитов урамы (50 м).

« ЭЙЕ» «КАРШЫ»

- кабул ителгән.

3. Җыенның нәтиҗәләрен ТР, Арча районы, Яңа Ашыт авылы, Вахитов урамы, 18 нче йорт адресы буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://arsk.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга кирәк: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин